**СОВЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

2024 елның «23» маеннан №46-348

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы халкының гендер составын исәпкә алып, кадрлар эшен оештыру турында мәгълүмат

Татарстан Республикасының Яңа Чишмә муниципаль районы Советы кадрлар секторы мөдиренең 2023 елда Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы халкының гендер составын исәпкә алып, кадрлар эшен оештыру һәм 2024 елга бурычлар турында мәгълүматын тыңлаганнан һәм фикер алышканнан соң, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасының Яңа Чишмә муниципаль районы Советы кадрлар секторы мөдире А.А. Бочарованың 2023 елда Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы халкының гендер составын исәпкә алып, кадрлар эшен оештыру һәм 2024 елга бурычлар турында мәгълүматын игътибарга алырга.

2. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының җирле үзидарә органнарына 2024 елда һәм аннан соңгы елларда тәкъдим итәргә:

2.1. Кадрлар сайлаганда һәм урнаштырганда, шул исәптән кадрлар резервын формалаштырганда, 2021 елгы Бөтенроссия халык санын алуның милли күрсәткече нигезендә муниципаль берәмлек халкы составының барлыкка килгән балансын сакларга;

2.2. Муниципаль органнарның җитәкчелек составы һәм оешма буенча конкрет эш алып бару өчен 2021 елда Бөтенроссия халык санын алуның территориаль күрсәткечләреннән 7-8 % читкә тайпылуның рөхсәт ителгән чиген сакларга;

2.3. Депутатлар корпусы составларын формалаштыру эше өчен 2021 елда Бөтенроссия халык санын алуның территориаль күрсәткечләреннән тайпылу рөхсәт ителгән чиген 10 % дип билгеләргә;

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында https://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе һәм җирлекләрнең вәкиллекле органнары белән хезмәттәшлек буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгы В. М. Козлов